ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шиланга авылы,
422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс (84379) 30-1-48

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс (84379) 30-1-48

24.10.2019 с. Шеланга 08

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Нариман авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 8 ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Нариман авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. «2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл җирлеге кешесеннән 1000 сум үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алдагы эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:

- Нариман авылының Эшче урамында юл төзергә

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Нариман авылы, Центральная урамы, 18 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

4. Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Шиланга авыл җирлеге Башлыгының «Югары Ослан муниципаль районы Шиланга авыл җирлегенең Нариман авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 2019 ел, 22 октябрь, 4 карары үз көчен югалткан дип санарга.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

**Югары Ослан муниципаль районы**
**Шилангы авыл җирлеге Башлыгы** **В.В.Майоров**